Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2023 ел № 4

Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Екатериновка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 8 ноябрендәге 110 номерлы Екатериновка авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 13 декабрендәге 31 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Екатериновка авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Югары Дәүләзәр авылында. Гражданнар җыенын 2023 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Тау өсте урамындагы 4 нче йорт янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2024 елда Югары Дәүләзәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Урта Дәүләзәр авылында. Гражданнар җыенын 2023 елның 11 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Яңа урамы буенча 5 нче йорт янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2024 елда Урта Дәүләзәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә

катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- - авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Екатериновка авылында. 2023 елның 11 ноябрендә 14.00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында (Совет ур., 23 йорт) гражданнар җыенын үткәрергә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- - авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.4. Нептун авылында. 2023 елның 12 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатьтә авыл клубы бинасында (Үзәк ур., 30 йорт) гражданнар җыенын үткәрергә.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Нептун торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Жуков